Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№12 (142)
30 июнь 2015 ел

# «Алтын» укучылар – КФУ лицеенда



Влад Михневский фотосы

**Барлык уку йортларында чыгарылыш тантаналары гөрли. КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге лицее дә искәрмә түгел! Чыгарылыш кичәсе 25 нче июньдә «УНИКС» концертлар залында узды. Инде традициягә әверелгән бәйрәмнең шундый зур масштабта үткәрелүе гаҗәп түгел. Лицей быел 15 яшен тутыра икән! Яшь булуына карамастан, белем бирү дәрәҗәсе бик югары. Быел гына лицей укучылары биш фәннән БДИ нәтиҗәләре буенча 100 балл җыюга ирешкән, ә уку йортын алтын медаль белән тәмамлаучылар саны – 7. Аларның исемнәре лицейның Мактау китабына беренчеләрдән булып теркәлгән. Чыгарылыш укучыларына да, университетыбызны тәмамлаган студентларга да яңа үрләр яулауда тырышлык һәм ихтыяр көче телибез.**

## • Вакыйгалар әзеннән

25 июньдә КФУда Берләшкән Гарәп Әмирлекләре кунаклары белән эшлекле очрашу узды. 40 ел дәвамында БГӘдә эшләгән **ДХЕЕРАДИМАЛЬ БАСТИМАЛЬ СИРОЯны**, Гарәп Әмирлекләренең сату-алу палатасы вәкиле **ДЖАСЕМ ИСА ХАЛЕД АЛЬ МУТАВВАНЫ** КФУ ректоры **ИЛШАТ ГАФУРОВ**, Икътисадый стратегик үсеш мәсьәләләре буенча проректор **МАРАТ САФИУЛЛИН**, Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры **АНДРЕЙ КИЯСОВ** һәм НОЦ фармацевтика директоры **ЮРИЙ ШТЫРИН** каршы алдылар. «Happy Umbrella Ltd» (ОАЭ), «Pharma Q Pry Ltd» (ЮАР), «Sandawana Mine Pwt Ltd» (Зимбабве) һәм «Bal Pharma Ltd» (Бангалор, Һиндстан) фармацевтика компанияләре директоры белдерүенчә, әлеге очрашуның максаты – КФУ һәм Дхеерадималь Бастималь Сироя арасында партнерлык килешүе төзү. Очрашуда дөнья күләмендә танылу алган һинд фармацевтика сәнәгате белән эшләү Казан (Идел буе) федераль университеты өчен гаять мөһим булуы билгеләнде.

• • • •

25 июньдә А.М. Бутлеров исемендәге Химия институтының киңәйтелгән Гыйльми советы узды. Утырыш барышында институт директоры **ВЛАДИМИР ГАЛКИН** узган уку елында башкарылган эшчәнлек буенча хисап тотты. 2014-2015 елның авыр килүенә карамастан, институтның уңышлары күп булуы ассызыкланды. Моннан тыш, Гыйльми советта ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы **РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ** кандидатурасын Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына тәкъдим итүне хупладылар.

• • • •

26 июньдә «Россия мөселманнары һәм матбугаттагы агымнар: үткәннән киләчәккә» дип аталган Габдерәшит Ибраһимов исемендәге III нче Халыкара симпозиум башланып китте. Чараның хөрмәтле кунагы Юныс Әмрә исемендәге Төркия институты рәисе **ХАЙАТИ ДЕВЕЛИ** булды.

Билгеле булганча, 2012 елда Казан (Идел буе) федераль университеты кысаларында Ю.Әмрә исемендәге Төркияне өйрәнү үзәгенә нигез салынды. Бүген үзәктә тел һәм илне өйрәнү буенча актив эш алып барыла. Очрашу барышында КФУ һәм Төркия институты арасындагы мөнәсәбәтләрнең ныгуы һәм якын арада Стамбулда Каюм Насыйри институты вәкиллеге ачылачагы билгеле булды.

• • • •

КФУда Япониянең RIKEN фәнни-тикшеренү үзәге, Джунтендо медицина университеты белән берлектә, Россиядә беренче IT-клиникага нигез салыначак. RIKEN үзәге директоры доктор **ЙОШИХИДЕ ХАЯШИЗАКИ** әйтүенчә, әлеге проект персонифицияләнгән диагностика куллану юлы белән авыруларны терелтүне максат итеп куя. Дәвалау һәм дарулар билгеләү барышында һәр пациентның ген үзенчәлекләре исәпкә алыныр дип көтелә. Яңа төр тикшеренүләр генетика өлкәсендәге сирәк очрый торган авыруларны кисәтергә ярдәм итәчәк.

• • • •

25-26 июньдә Мәскәүдә БРИКС илләре эш төркемнәренең рәсми очрашуы узды. Чарада төрле ил министрлыклары, илчелек, фәнни һәм академик берләшмәләрдән 50дән артык вәкил катнашты. Казан (Идел буе) федераль университетын уку-укыту эшчәнлеге буенча проректор **ДМИТРИЙ ТАЮРСКИЙ** тәкъдим итте. Утырышта БРИКС университет челтәрләрен булдыру мәсьәләсе каралды. Россия Фән һәм мәгариф министрлыгының матбугат хезмәте белдерүенчә, ил вәкилләре «БРИКС университетлары челтәрен булдыру һәм функцияләштерү принциплары» проектына ачыклык кертергә тиешләр.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

● Тәҗрибә уртаклашу

# Университет үзгәрешләргә әзер

Айгөл АБДРАХМАНОВА

**Күптән түгел генә КФУ «Юл карталары» буенча хисап тоткан булса, бүген исә университет данын чит илләргә дә тарату өлкәсендә эш алып бара һәм Россиянең иң алдынгы уку йортлары белән тәҗрибә уртаклаша.**

Белем бирү программаларын чит илләргә таныту өлкәсендә фикер һәм тәҗрибә алышу өчен, КФУ Россиянең иң алдынгы 15 югары уку йорты вәкилен кабул итте. Катнашучылар өч көн дәвамында түгәрәк өстәл, мастер-класс һәм тренингларда катнашып, үзара тәҗрибә уртаклаштылар. Кунаклар билгеләвенчә, КФУның һәр үзәге, һәр лабораториясе яңа технологияләр белән җиһазландырылган һәм заман таләпләренә туры килә торган белгечләр әзерләргә сәләтле.

«5-100» проектының төп максаты – университетларның дөньякүләм рейтингында аерым урын алу. Уку йортының инглиз телле мохиттә үз урынын табуы халыкара багланышлар урнаштыруга зур ышаныч булып тора. Семинар-конференцияләр барышында КФУда лекцияләрнең инглиз телендә укылуы һәм студентларга чит телләр өйрәнү өчен күбрәк сәгатьләр бүлеп бирелүе ассызыкланды. Моннан тыш, КФУның мәктәп укучылары белән дә даими эшчәнлек алып баруы, инглиз телендә конференция, түгәрәк өстәлләр һәм фестивальләр оештыруы да искәртеп үтелде.



■ «5-100» проекты кунаклары. Инна Басыйрова фотосы.

«5-100» проектына багышланган 10 нчы семинар-конференция кысаларында Интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен (ИЭН) таныту өлкәсендә барлыкка килә торган авырлыклар һәм аларны чишү юллары турында фикер алыштылар. Университет вәкилләре сүзләренә караганда, Интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен тәкъдим итү һәм алга җибәрү өчен, уртак мәйдан булмау һәм халыкара патент алуның гомуми нигездә финансланмавы шактый зур авырлыклар тудыра икән.

19 июньдә уздырылган түгәрәк өстәл барышында КФУ ректоры **Илшат Гафуров** бүгенге көндә университетның өр-яңа тарихы язылуы турында сөйләде: ул Казан шәһәре уку йортларын берләштерә, бүген Россиянең иң зур 10 университеты исемлегенә керә. Бүгенге көндә КФУда 48 мең студент берничә дистә белгечлек буенча белем ала. Соңгы елларда биомедицина, фармацевтика, нефть эзләү һәм эшкәртү, нефтехимия, инфокоммуникацион һәм космик технологияләр буенча 150 дөньякүләм дәрәҗәдәге лаборатория ачылуы искәртелде. Ректор әйтүенчә, КФУ 2013 нче елда, башка уку йортлары тәҗрибәсенә таянып кына түгел, ә республикабызның үсеш перспективасы булган өлкәләренә дә игътибар итеп, «юл картасы» төзи башлаган иде.

Әле күптән түгел генә башланып киткән эшнең нәтиҗәләре куандырырлык. КФУның QS дөньякүләм рейтингында соңгы елда гына да 50 баскычка күтәрелүе шуңа дәлил. БРИКС илләре билгеләвенчә, федераль дәрәҗәдәге югары уку йортлары арасында КФУ беренчелекне яулады.

РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Стратегия, анализ һәм фараз департаменты директоры **Григорий Андрющак** үзенең чыгышында КФУның үзгәрешләргә әзер булуын, партнер һәм инвесторлар белән актив эш алып баруын югары бәяләде һәм, «5-100» проектында катнаша торган башка уку йортлары белән чагыштырганда, алдарак баруын билгеләп үтте.

● Туган тел сагында

# «Амина плачет, что үкер»




Альбина БӘШИРОВА, Руфинә ГАБДРАХМАНОВА

**Таныгансыздырмы, юкмы, бу – һәр татар баласы яттан белгән Әминә турындагы шигырьнең беренче юлы. Варварлыкта гаепләргә ашыкмагыз, безнең сүзләр түгел бу, «Яндекс. Переводчик» сервисында яңа гына дөнья күргән татар теленә онлайн тәрҗемә итү хезмәте кулланучыларны шундый «иҗат җимешләре» белән шаккаттыра.**

Милләте, теле язмышына битараф булмаган татарлар һәм татар теленә өйрәнүгә күңел куйган кешеләр өчен мөһим вакыйга булды: 2 нче июньдә Яндексның «Тәрҗемәче» сервисы исемлегенә татар теле дә өстәлде. Хәзер теләгән һәр кеше үз язмаларын дөньяның 47 теленнән татарчага һәм киресенчә тәрҗемә итә ала. Тик бу хезмәтнең нәтиҗәләре дөреслеге һәм төгәллеге белән әлегә сезне куандырудан бигрәк көлдерер генә, чөнки яңа гына татарча өйрәнгән система кайвакыт тузга язмаган тәрҗемә вариантлары тәкъдим итә.

Июнь ае башында **Данил Сафаров** Facebook социаль челтәрендә, Яндекс тәрҗемә иткән сүзләрне китереп, хәбәр куйган иде. Ул чакта «дәфтәр» – «книга», ә «сабырлык»-«терпения» иде. Әйтергә кирәк: хәзер инде мондый «төгәлсезлекләр» төзәтелгән. Һәр сүз башка телдәге үз эквивалентын тапкан. Хәтта инглиз теленә дә тәрҗемә дөрес: дәфтәр – notebook, сабырлык – patience..

### «Яндекс.Тәрҗемәче» татар телен өйрәнә

«Тәрҗемәче» хезмәткәрләренең блогындагы аңлатмалардан күренгәнчә, проблема барлыгы инкяр ителми. «Татар теленең морфологиясе бик катлаулы, шуңа күрә ул – автоматик тәрҗемә өчен иң авыр телләренең берсе», – дип искәртә алар. Шулай ук интернет киңлекләрендә татар текстларының бик аз булуы да ассызыкланган. Автоматик тәрҗемәнең статистика принцибын кулланып эшләвен исәпкә алсак, бу кимчелекне иң хәлиткечләреннән берсе дип атарга мөмкин. Чөнки Яндексның автоматик тәрҗемәчесе, бер үк төрле текстларны төрле телләрдә чагыштырып, сүзләрнең иң еш кулланылган вариантын тәкъдим итә. Интернет киңлекләрендә татар текстларының аз булуы тәрҗемә сыйфатына турыдан-туры йогынты ясый дигән сүз.

Әлбәттә, Яндекс бу эшне гади статистикага нигезләнеп кенә башкармый. Татар теленә тәрҗемә эшен Татарстан Җөмһүриятенең Фәннәр академиясе галимнәре контрольдә тота. Димәк, киләчәктә, бу системаның татар теленә кагылышлы өлешендә проблемалар тулысынча бетмәсә дә, сизелерлек дәрәҗәдә кимер, дигән фаразга урын бар.

### Татар теле интернет теле булырмы?

Яндекс сервисы тәкъдим иткән статистикага караганда, интернет сәхифәләренә татарча-русча тәрҗемәне эзләп керүчеләр саны аена 50-60 меңнән артып китә. Билгеле, мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге Татарстанда яшәүчеләрдән килә. Шулай ук Ульяновск, Башкортстан һәм Кырым кешеләре дә татар теле белән кызыксына икән. Татар милләте вәкилләренең гомуми саны 7 млн. тирәсе булуын исәпкә алсак, сыйфатлы тәрҗемәчегә ихтыяҗ зур булачак.

Татар телен «кухня теле» дип лаф оручыларга салкын гына бер җавап булды бу. Чөнки безнең заманда, халык куллана торган тел интернетта юк икән, аның, чыннан да, киләчәге юк, дияргә була. Ә хәзер «боз кузгалды», бары тик бу мөһим проектның ярты юлда тукталып калуына гына юл куймаска кирәк. Ул, иң актуаль мәсьәләләрнең берсе буларак, һәрвакыт игътибар үзәгендә булырга тиеш. Мактапмы, хурлапмы, көлепме – ничек кенә булмасын, «Яндекс. Тәрҗемәче»нең татар телле хезмәте, аның проблемалары турында даими рәвештә искәртеп тору зарур.

### Татар теленә тәрҗемә итүдә беренче адымнар

Интернетның татар телен үз итәргә тырышу омтылышлары элек тә булган. Аерым кешеләр һәм актив төркемнәрнең татар теленә тәрҗемә проектлары тәкъдим итүләре киң җәмәгатьчелеккә күптәннән билгеле. Мисал өчен, Чаллы шәһәрендә яшәүче журналист **Зөбәер Мифтахов** Microsoft Word өчен «Татарча» исемле тәрҗемә программасын эшләгән. Бу программа, Яндекс һәм Google тәкъдим иткән аерым сүзләрнең генә түгел, ә тулы текстларның мәгънәви тәрҗемәсен дә башкарырга мөмкинлек бирә. Программа шактый күптән, 2008 елда ук төзелгән булуына карамастан, халык арасында киң кулланылыш тапмады. Сәбәбе проектны финанслау мәсьәләсендәдер, мөгаен.

Хәзерге көндә тагын бер милләттәшебез – **Динар Корбанов** та татар телен халыкара дәрәҗәгә күтәрү проблемасы белән мәшгуль. Ул «Tarjima» дип аталган инглиз-татар тәрҗемә программасын ясауга алынган, тик шулай ук бөтен эш акчага килеп төртелә. Динар хәбәр иткәнчә, ул гамәлгә ашырачак программаның эш алгоритмы Яндекс һәм Google тәрҗемәчеләреннән аерыла, шуңа күрә тәрҗемә продукты төгәлрәк, камилрәк булачак. Ләкин бу киләчәк кайчан җитәр, билгесез.

ТР Фәннәр академиясенең «Гамәли семиотика» фәнни-тикшеренү институты озак еллар инде компьютер, информацион технологияләр ярдәмендә татар теленә өйрәтү өстендә эшли. Киләчәккә юнәлгән планнар шактый җитди үсеш-үзгәреш китерер төсле: 2020 елга яхшы машина тәрҗемәсе өчен кирәкле 100 млн. сүзформадан торган база тупланырга тиеш икән.

Татарстанда дәүләт тарафыннан шактый зур күләмдә финанс ярдәме алып оештырылган проект та бар. Сүз дәүләт телләрен үстерү программасына нигезләнеп эшләнгән «Ашыгыч лингвистик ярдәм хезмәте», ягъни «Тылмач» проекты турында бара. Аңа 2014 елда нигез салынган, җитәкчесе – галим **Ренат Латыпов**. Проектның төп эшен КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты хезмәткәрләре башкара. Алар ярдәмендә татарча-русча һәм русча-татарча тәрҗемәләр ясарга була. Бу «ашыгыч ярдәмнән» файдалану өчен, турыдан-туры сайтка мөрәҗәгать итәргә, я электрон адреска хат язарга кирәк. Мөрәҗәгать итүче белән робот түгел, ә тере кешеләр – тел белгечләре аралаша. Димәк, бу хезмәт тәкъдим итә торган тәрҗемәләр, дөрестән дә, югары сыйфатлы, камил телдә булачак.

Татар телен чит тел буларак укытучылар, бераз булса да, иркен сулап куйды.

### Галимнәр фикере

«Гамәли семиотика» фәнни-тикшеренү институты директоры, КФУ профессоры **Җәүдәт Сөләйманов**: «Яндекс. Тәрҗемәче» турында билгеле бер нәтиҗәләр чыгарырга иртәрәк. Бу – беренче адымнар гына. Эшлисе эшләр күп әле. Баланың урта белем алуы 11 елга исәпләнгән булса, Яндекс татарчага һәм татарчадан тәрҗемә итү курсының 1 нче сыйныфында гына».

**Рәшат Якупов**, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты:

«Бу – татар теле өчен интернетта иң кирәкле әйберләрнең берсе. Тәрҗемәнең сыйфаты яхшырса, аңа ихтыяҗ көннән-көн арта гына барачак. Телне өйрәнүчеләргә мондый оператив тәрҗемә сервислары бик кирәк.

Мисал өчен, инглиз телен өйрәнгәндә, без мондый төр машина тәрҗемәсеннән файдаланабыз. Аның дөресме, түгелме икәнен кайчак уйлап та тормыйбыз. Чынлыкта исә, ул тәрҗемә дә идеаль түгел, «чыктым аркылы күпер» формалары еш очрый. Ләкин ул нинди генә китек булмасын, җәмгыятьтә аңа ихтыяҗ бар. Халык сорый һәм җавабын да таба».

***P.S.** Татарстан IT-өлкәнең алдынгы позицияләрендә бара. Әлеге лидерлык халкыбыз өчен әһәмиятле булган бу мәсьәләне чишүдә үз ролен уйнаячак әле. Һәм, кем белә, бүген татар телен өйрәнүдә «беренче сыйныфта гына укучы» «Яндекс. Тәрҗемәче» бу курсны бик тиз генә, экстерн рәвештә тәмамлый алыр.*

• Әңгәмә

# «Проекттан кәнфит ясадык»

**Диләрә БАТРШИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Татарстанның 30 студенты Чехиягә сәяхәт кылган, Германиянең Берлин шәһәрендә республикабыз флагын күтәргән. Алар арасында Казан федераль университеты студентлары да бар. Әлеге вакыйганың сәбәбе сезгә дә кызыклыдыр! Барлык сорауларга Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты Айсылу Мөбәракшина җавап бирде.

**– Айсылу, Чехиягә сезне нинди җилләр ташлады?**

– Бу сәяхәтебез «Сәләт» Прага мәктәбе кысаларында үтте. Без, сайлап алу турын үткән 30 студент, үз проектларыбызны яхшырту максаты белән Прагага очтык. Сүз уңаеннан, «Сәләт» Прага мәктәбе (Selet Prague School) – ул укыту программасы. Биредә 20 дән 35 яшькә кадәрге нинди дә булса проект идеясен тудыручы яки чынга ашырырга мөмкинлекләре булган инновацион проект җитәкчеләре катнаша ала. Бу эшнең нәтиҗәсе булып, киләчәктә иҗтимагый җаваплы бизнес төзү тора.

2014 нче елда кертелгән үзгәрешләрдән соң, быел, 2015 елда, «Сәләт» Прага мәктәбе җиденче тапкыр үткәрелде. Бу программада катнашкан 30 студентны Татарстан Республикасы өчен яхшы кадрлар булыр дип әзерлиләр. Башкача әйткәндә, «Сәләт» Прага мәктәбе – нинди дә булса проект белән янучылар өчен идеаль даирә. Ул үз проектыңны төзү, тормышка ашыру, профессионаллар тарафыннан фикерләр ишетү, соңыннан ул проектны куллануга чыгару өчен менә дигән киңлек.




**– «Сәләт» Прага мәктәбенә эләгү өчен нинди юллар үтәргә кирәк?**

– Иң беренче чиратта, үз проектың кирәк. Ул төрле өлкәдә була ала: фән, аш-су, технология һәм башкалар. Быел, мисалга, кафе оештыру, телефоннарга кушымта язу, фәнни үзәк һәм хәтта татарча квест проектын төзүчеләр булды. Әгәр дә сине сайлап алсалар, әңгәмә туры үтәсең. Ул өч өлештән тора: беренчесе – татар телендә, икенчесе – инглиз телендә аралашу, өченчесе – жюрига үз проектыңны рус телендә тәкъдим итү. Быел 100дән артык гариза кабул ителде, әңгәмә турына 90 кеше килде. Шулар арасыннан бары тик 30 студент кына Чехиядә уку бәхетенә иреште. «Сәләт» Прага мәктәбе программасы ел саен уздырыла, әмма биредә бер тапкыр гына катнашырга мөмкин.

**– Үз проектың белән таныштыр әле: ул нидән гыйбарәт иде?**

– Минем проект – ул сәләтле балалар өчен белем бирү үзәге. Хәзер фән белән кызыксынган, укырга теләге булган балаларга, миңа калса, мәктәптә генә биргән белем җитми. Аларны аерым бер үзәккә туплап, өстәмә белем бирергә кирәк. Мин әлеге белемне балаларга кызыклы итеп җиткерүче даирә барлыкка китерү проектын төзедем.

**– Чехиядә үткән ике атнада сез нәрсә белән шөгыльләндегез?**

– Без Прагадан 40 чакрымда урнашкан Созава шәһәрчегендә пансионатта яшәдек. Укулар биредә дә, Чехиянең башка шәһәрләрендә дә үтте. Иң мөһиме – үз проектыбыз өстендә эшләдек: аның аспектларын, картасын төзедек, нечкәлекләрен барладык. Ягъни проекттан кәнфит ясадык. Күбесенчә көнгә ике тапкыр укыдык: спикерлар биремнәр бирде, без я үзебез, я команда белән аларны бергәләп башкардык.

**– Кызыклы сәяхәт, очрашулар да аз булмагандыр?**

– Чехия иленең Прага, Брно, Германиянең Берлин шәһәрләрен күрдек. Иң истәлекле вакыйга 9 нчы май көнне булды: без Берлин шәһәрендә рейхстагка кердек (анда гади көнне дә керүе авыр икән), солдат һәйкәленә чәчәкләр куйдык. Биредә безне диварларда солдатлар калдырган язулар тетрәндерде. Алар арасында татар исемнәре дә бар иде.

Очрашулар кызыклы һәм файдалы булды: бизнес-инкубаторда проектлар белән эшләүче яшьләр, Россиянең Чехия Республикасындагы сәүдә вәкиле Сергей Ступарь һәм Татарстанның Чехия Республикасындагы сәүдә вәкиле Зөфәр Абделгалиев, Unifer компаниясе җитәкчесе Станислав Галик, MAKRO нәшрияты, Азатлык радиосы җитәкчесе Алик Гыйльми, Чехиядәге милләттәшләр һәм башкалар белән аралаштык.

Дәресләргә килгәндә, ике укытучыны аерып әйтәсем килә. Сәләттә уку-укыту үзәге җитәкчесе Анна Фельдман безгә үз-үзебезне аңларга ярдәм итте, ә чит ил укытучыларыннан креативлык һәм инновация өлкәсендә халыкара эксперт, Track2 тренинг компаниясе җитәкчесе Трейси Фаррелл креативлыкка өйрәтте.

**– Прага нәрсә белән исеңдә калды?**

– Прага борынгы шәһәр булуы белән игътибарны җәлеп итте, кабатланмас матур бинаталары белән сокландырды. Гид әйтүенчә, шәһәргә сугыш килеп җитмәгән. Шуңа күрә барлык иске биналар сакланып калган. Биредә хайваннарга карата мәрхәмәтлелек өстенлек итә: шәһәр сулыкларында аккошлар, үрдәкләр йөзә, офисларында эт ята. Шуңа да карамастан, Прага бик чиста шәһәр! Тирә-якта яшеллек, чәчәкләр... Чехия һәр төрле халык өчен яраклашкан ил: яшелчә белән генә тукланучылар өчен кафелар бар, бәяләр арзан, акча алыштыру пунктлары күп.

**– Чехиядә булган берәр кызыклы вакыйга турында әйтеп кит әле.**

– Кызыклы вакыйгалардан шул истә калган: безгә моңа кадәр бер тапкыр да башкармаган эшне эшләргә куштылар. Бу, үз чиратында, синнән нинди дә булса кыюлык таләп итәргә тиеш иде. Кемдер яңгырлы көнне салкын суга сикерде, ә без, кызлар, балконга чыгып, Чехияне яңгыратып, татарча җырладык.

**– «Сәләт» Прага мәктәбе эше шуның белән тәмаммы?**

– Әлбәттә, юк. Тиздән Сәләт йортында проектларны яклау көтелә. Бу – «Сәләт» Прага мәктәбе программасының нәтиҗәсе булачак. Биредә инвесторлар синең проектыңны сайлап алырга мөмкиннәр. Ә бу – үз проектыңны чынга ашыру финансланачак, дигән сүз. Әлбәттә, акчаны, булдыра алсаң, үзең дә таба аласың, чикләр юк. Мисалга, узган ел бер кыз үз тырышлыгы белән телләр мәктәбе ачты.

Шуны әйтәсем килә: хәзер мөмкинлекләр бик күп. Аларны кулдан ычкындырмаска гына, файдаланып калырга кирәк.

**– Бу сәяхәт сиңа нәрсә бирде?**

– Чехиядә булып кайтуыма мин бик шат. Мондый мәктәпне Татарстанда гына да үткәрергә мөмкин. Әмма Прагада оештыру күпкә кулай. Әгәр шулай булмаса, беренчедән, без халыкара укытучылар белән таныша алмас идек. Икенчедән, синең бөтен эшең, укуың Казанда гына кала, башка проблемалар белән танышмыйсың, үзең өчен генә укыйсың, проектың өстендә генә эшлисең. Прагада без белем алып кына калмадык, ә рухи яктан үзгәреп, илһамланып та кайттык.

• Белдерү

**КАЗАНСКИЙ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ОБЪЯВЛЯЕТ**

***конкурс на замещение должностей профессорско-преподавательского состава:***

● **в Институт психологии и образования КФУ:**

● **доцента** кафедры методологии обучения и воспитания - 0,5 ставки, 1 вакансия;

● **в Приволжский межрегиональный центр повышения квалификации и профессиональной переподготовки работников образования КФУ:**

● **доцента**
- отделения управления и экономики образовательных учреждений - 1 ставка (1 вакансия);
- отделения общего образования - 3 ставки (3 вакансии);
- отделения общей и коррекционной педагогики и психологии - 2 ставки (2 вакансии);
- отделения дошкольного и начального образования - 1 ставка (1 вакансия);

● **старшего преподавателя:**
- отделения управления и экономики образовательных учреждений - 1 ставка (1 вакансия), 0,5 ставки (1 вакансия);
- отделения общего образования - 2 ставки (2 вакансии);
- отделения общей и коррекционной педагогики и психологии - 1 ставка (1 вакансия);
- отделения дошкольного и начального образования – 2 ставки (2 вакансии).

● **в Общеуниверситетскую кафедру физического воспитания и спорта:**

● **преподавателя кафедры –** 1 ставка (1 вакансия).

● **в Институт непрерывного образования:**

● **доцента:**
- учебного центра дополнительных образовательных ресурсов – 0,1 ставки (1 вакансия), 0,5 ставки (1 вакансия) (всего 0,6 ставки);

● **преподавателя:**
- учебного центра дополнительных образовательных ресурсов – 0,5 ставки (1 вакансия), 0,1 ставки (1 вакансия), 0,1 ставки (1 вакансия) (всего 0,7 ставки).

........................................

***конкурс на замещение должностей научно-педагогических работников*** *для выполнения работ в рамках* ***Плана мероприятий по реализации Программы повышения конкурентоспособности*** *(«дорожной карты»)****:***

● **в Институт геологии и нефтегазовых технологий КФУ:**
- старшего научного сотрудника - 0,25 ставки (1 вакансия) НИЛ «Фазового анализа геоматериалов»;
- младшего научного сотрудника - 2 ставки (2 вакансии) НИЛ «Внутрипластовое горение»;
- младшего научного сотрудника - 2 ставки (2 вакансии) НИЛ «Разработки полимер - битумных органических вяжущих».

● **в Институт физики:**
- младшего научного сотрудника - 0,25 ставки (1 вакансия), 0,25 ставки (1 вакансия), (всего 0,5 ставки) НИЛ Исследований ближнего космоса;
- старшего научного сотрудника - 0,5 ставки (1 вакансия) НИЛ «Физика и механика многофазных сред».

● **в Институт вычислительной математики и информационных технологий:**
- научного сотрудника - 3 ставки (3 вакансии), младшего научного сотрудника - 1 ставка (1 вакансия) НИЛ «Квантовая информатика».

● **в Набережночелнинский институт (филиал):**
- ведущего научного сотрудника – 0,5 ставки (1 вакансия), старшего научного сотрудника – 0,5 ставки (1 вакансия), 0,5 ставки (1 вакансия), (всего 1 ставка), младшего научного сотрудника – 0,5 ставки (1 вакансия) Научно-исследовательской лаборатории OpenLab «Разработки и исследования перспективных материалов».

● **в Институт фундаментальной медицины и биологии:**
- младшего научного сотрудника - 1 ставка (1 вакансия) НИЛ «Экстремальная биология».
- младшего научного сотрудника - 0,5 ставки (1 вакансия), 0,5 ставки (1 вакансия), 0,5 ставки (1 вакансия) (всего 1,5 ставки), старшего научного сотрудника - 0,25 ставки (1 вакансия), НИЛ OpenLab «Двигательная нейрореабилитация».

**ЗАЯВЛЕНИЯ** вместе с документами, подтверждающими квалификацию кандидата, принимаются в Управлении кадров КФУ (420008, г. Казань, ул. Кремлевская, 18, каб.136 главного здания).

Информация о конкурсе, о сроках и месте проведения конкурса размещается на сайте Управления кадров официального портала КФУ kpfu.ru.

• Җәйге ял

# Якыннарыгыз белән бергә булыгыз!

**Зәлия ХУҖИЕВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Ялларны дуслар белән бергә оештырыгыз. Күп кенә студентлар туган якларыннан читтә укыйлар. Моның уңайсыз ягы да бар, чөнки өйдә калган дуслар белән еш очрашып та, аралашып та булмый. Интернет, телефон элемтәсе булуга карамастан, кеше белән кара-каршы утырып сөйләшү үзе бер гомер. Шуның өчен җәйге ялыгызны туган ягыгыздагы дусларыгыз белән бергә уздыру турында алдан ук сөйләшеп куегыз. Акча ягыннан кыенлык кичермәсәгез, бергәләшеп чит илгә ял итәргә барырга мөмкин яисә Россия буйлап сәяхәткә чыгарга да була.

Каникулда гел ял итәргә генә димәгән, ике-өч ай буе ялдан арып китсәгез, бу вакытны чит телләр өйрәнүгә багышларга да мөмкин. Кайбер студентлар, чит илгә китеп, андагы махсуслашкан мәктәпләрдә шул ил телен өйрәнәләр, шул телдә сөйләшә торган гаиләдә яшиләр. Мондый ялның, рәхәтлегеннән кала, файдасы да бар.

Ялларны гаиләгез белән бергә үткәрергә тырышыгыз, чөнки уку вакытында сез болай да бик сирәк күрешәсез. Бергә-бергә кинотеатрларга, спектакльләргә йөрегез, урманга барыгыз, су буена төшегез.



● Фикер

# Профессия буенча эшләячәксеңме?

Бүген чыгарылыш студентларын борчыган проблема – ул эш табу. Әйе, тапталган, изелгән, ләкин үзенең актуальлеген югалтмаган четерекле мәсьәлә 4 нче һәм 5 нче курсларга тынгы бирми. Студентларның 80-90%ы «Профессияң буенча эшләячәксеңме» дигән сорауга, ни кызганыч, үзләре дә җавап таба алмыйлар.

**Әлмирә ӘГЪЗАМОВА**, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Статистик белешмәләрне карасак, бүгенге көндә илебездә, югары уку йортларын тәмамлап, кулларына диплом алган студентларның 60%ы үз профессияләре буенча эшләми. Шушы студентларның күбесе, инде уку дәверендә үк, «без алган һөнәребез буенча эшләмәячәкбез, монда диплом өчен генә укыйбыз, безнең эш урыннары инде әзер» дип игълан итәләр.

Экспертлар фикеренчә, әлеге проблеманың барлыкка килүендә бюджет уку системасы гаепле. Әйе, безнең күпләребез өчен әлеге бушлай уку урыннары кадерле һәм кыйммәтле, тик эксперт-лар моның белән килешми. «Укуга сарыф итегән бюджет акчаларының яртысы диярлек җилгә оча, һәм без моны ел саен күреп торабыз. Уку аша югары үрләргә, профессиональ карьерага ирешү урынына, ата-ана һәм студент беренче урынга ничек булса да университетка укырга керүне куя, ә эш ягы үзеннән-үзе, таныш-белешләр ярдәме белән хәл ителәчәк дип белдерәләр.



Мондый фикерләр дөрес түгел һәм студентларның эшсезлеге дә нәкъ шуннан барлыкка килә», – ди экспертлар.

Студентларның профессия буенча эшләмәүләренең тагын бер сәбәбе – ул аз күләмле хезмәт хакы һәм уку вакытында башка төр эшчәнлек белән мавыгу. Күпләр икенче, өченче курска җиткәч, үзләренең һөнәрне дөрес сайламаганнарын аңлыйлар, ләкин бик азлары гына уку урынын алмаштыра. «Бер кергән, укып бетерәм инде, мондагы укытучылар да үзебезнеке, төркем, коллектив белән дә мөнәсәбәтләр әйбәт, җайлашкан» дип, үз урыннарында калалар.

Булачак профессиянең хезмәт базарында престижлыгы, профессиональ карьера буенча үсү мөмкинлеге, уку дәверендә алынган белемнең җитү-җитмәве, булачак профессиянең кызыклы һәм җәмгыять өчен кирәк булуы – бу факторлар чыгарылыш студентына киләчәк профессиясен сайлауда зур йогынты ясый.

Яшьләр эшкә урнашырга барганда, иштектән килеп керүгә, беренче сорауның «тәҗрибәң бармы» дип яңгыраячагын белә һәм күпләр әлеге сорауга җавапсыз кала. Әлеге сорауга «әйе» дип әйтер өчен, студент уку дәверендә үк эшли башларга тиеш, булачак һөнәре өлкәсендә әзме-күпме тәҗрибә туплаган булса, әлбәттә, аның үзенә дә җиңел булачак: киләчәктә дә, эшкә урнашкан вакытта да.

Студентлар беренче тәҗрибәләрен уку дәверендәге практика чорында туплый алалар. Тик мондый мөмкинлек һәрбер институтта да бирелми. Бу яктан без, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты студентлары, бәхетле дисәм дә, ялгышмам. Чөнки, беренче курстан алып, без, уку белән берләттән, практиканы да үзләштерәбез. Һәм, әйтергә кирәк, әлеге чара күп студент-журналистлар өчен эш урыны белән бәйле проблеманы хәл итәргә булыша. Студентларны, рәхәтләнеп, практика үткән газета редакцияләренә, республика телевидениесенә эшкә чакырып калалар. Тик студент әлеге мөмкинлектән дөрес һәм рациональ итеп файдалана алачакмы – монысы бары тик аның үзеннән һәм киләчәккә булган теләкләреннән генә тора!

Чыннан да, әзләгән, укыган кешегә һәрчак эш табыла дип уйлыйм мин, бары тик теләк кенә кирәк. Әинде сиңа куйган шартлар белән килешү-килешмәү, тәкъдим ителгән вазыйфадан «миңа бу гына җитми» дип баш тарту – бу инде икенче мәсьәлә.

● Белми калма!

## Абитуриентлар колагына

БДИ чоры тәмамланды, инде нәтиҗәләр билгеле. Димәк, Россиядәге башка югары уку йортлары белән берләттән, Казан федераль университеты да яшь көчләргә, абитуриентларга үз ишекләрен ачты.

Быел кабул итү комиссиясе эшчәнлеге узган елгыдан аерылып тора: беренчедән, документларны кабул итеп алу көннәрендә үзгәрешләр бар. Икенчедән, абитуриентларның конкурс исемлеге **27 июльдә**, ә КФУга кабул ителүчеләрнең исемлеге **30 июльдә** КФУ сайтында урын алачак. Өченчедән, кабул итү быел ике баскычтан тора. Беренче дулкын белән кабул ителүчеләрнең исемлеге – **4 августта**, ә икенче дулкынныкы **7 августта** көннәрендә билгеле булачак.

Тагын бер мөһим яңалык: **мәктәпне моннан берничә ел элек бетерүчеләр уку йортына бары тик БДИ нәтиҗәләре буенча кабул ителә.**

Тулырак мәгълүматны КФУның рәсми сайтыннан таба аласыз.

● Спорт – 2015

# Волонтерлык серләре

**Раил САДРЕТДИНОВ**, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Казан – спорт шәһәре. 2013 елгы Универсиада, һәрдаим үткәрелеп торган спорт чаралары моңа ачык мисал. Быел Казаныбыз моны тагын бер тапкыр исбат итәчәк, чөнки 16 нчы тапкыр үткәрелә торган су төрләре буенча Дөнья чемпионаты спорт, су һәм җәйне сөючеләрне башкалабызга җыя. Бу зур чара 24 нче июльдән 16 нчы августка кадәр дәвам итәчәк.

Шунысы мөһим – әлеге чемпионат элек СССРда да, Россиядә дә үткәрелмәгән. Спортчылар алты төрдә (болар арасында да гади йөзү, ачык сулыкта йөзү, суга сикерү һәм хайдайвинг, синхрон йөзү бар) көч сынашачак. Бу ярышлар өчен шәһәрдә 3 мәйдан әзерләнә: Kazan arena стадионы, Казансу елгасы яр буе һәм Су төрләре спорты сарае. Боларда ярыш уты, әйткәнемчә, 24 нче июльдә кабыначак. Әбүген киң масштаблы әзерлек эшләре бара.

Универсиададагы кебек үк, спортчыларга һәм кунакларга волонтерлар ярдәм итәчәк. Әмма, 2013 ел вакыйгасыннан аермалы буларак, аларның саны бары 2500 генә. Күбесе КФУ студентлары булуы – сөенечле күренеш. Быелгы җәйне кызыклы һәм файдалы үткәрергә, ягъни волонтер исемен горур йөртергә әзерләнүчеләр арасында **Гөлназ Гатауллина** (*фотода*) да бар. Гөлназ – Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар филологиясе бүлегеннән, чыгарылыш курс студенты. Бүген аның өчен дулкынландыргыч мизгелләр – дәүләт имтиханнары, диплом яклау инде артта калган. Ә җәй көтелмәгән сюрпризларга бай булыр, мөгаен, ди ул.

**– Гөлназ, моңарчы волонтер булганың бар идеме? Истәлекләрең белән уртаклашсаң иде.**

– Бик күп чараларда волонтер булырга туры килде, һәрбер чара үзенә күрә кызык, үзенә күрә мавыктыргыч. Шуларның иң истәлеклесе, әлбәттә, Универсиада-2013. Ярышларның соңгы көннәрендә кич белән Универсиада авылында Change («ченч» – алмашу) башланды. Спортчылар киемнәре, атрибутикалары белән алмашты. Гарәп спортсмены Хәбиб анлатканча, спортчылар арасында бер традиция икән бу. Шулай алмашкан әйберләр истәлеккә кала һәм ул илгә чакырып тора, диләр. Миндә бик күп илләрнең значоклары истәлеккә калды, Оман, Төркия, Малайзия, Тайланд, Бразилия һ.б. ил вәкилләреннән истәлеккә калган футболка, бейсболкаларны да кадерләп саклыйм. «Алмашу» вакытында бик күп спортчылар белән таныштым, кайберләре белән бүген дә аралашабыз. Бигрәк тә мөселман иле вәкилләре бик теләп һәм зур хөрмәт белән аралаша иде. Мөселман иканебезне белгәч, инде бөтенләй «oh, my sister!!!» (о, кыз туганым) дип, тагын да якынрак күрәләр иде.

**– Гөлназ, быел үтәчәк бу зур чарада волонтер булырга теләк белдерүеңнең сере нәрсәдә?**

– Әлеге чара минем өчен Универсиада-2013 кебек үк кызыклы, якты, онытылмас истәлекләр вәгъдә итә. Мондый чаралар һәрвакыт яңа танышларга һәм тәҗрибәгә бай була. Шуңа күрә мин үз иреем белән волонтер булырга теләк белдердем.

**– Чемпионатка әзерлек башландымы инде?**

– Әйе, 5 июнь көнне УНИКС концертлар залында волонтерларның беренче җыелышы узды. Барлык таләпләр, тәртипләр белән таныштырдылар. Быел һәр волонтер наркотест үтәргә тиеш һәм, универсиададан аермалы буларак, һәр волонтерның прививкалар сертификаты булырга тиеш.

**– Булачак чара волонтерларга тагын нинди таләпләр куя?**

– Таләпләр Универсиададагы кебек үк: миләтара, расаара түземлелек, тыйнаклык, ярдәмчеллек һәм ягымлылык. Кызлар өчен тышкы кыяфәткә карата таләпләр бар: чәч тузгып тормасын, бизәнү чаралары да артык күзгә ташланмаска тиеш. Бәхәсле очракларда да үзеңне тота белү мөһим.

**– Волонтер булу синең өчен нәрсә ул? Бу йөрәк кушуымы, әллә...**



– Волонтер булу – ул буш вакытыңны файдалы итеп үткәрү, тәҗрибә туплау һәм, иң мөһиме – дуслар һәм яхшы кешеләр белән аралашу, алар белән бергә булу. Чөнки волонтер эшен бары тик киң күңелле кешеләр генә сайлый дип уйлыйм. Әлеге тәҗрибәнең тормыш юлымда бик зур мөмкинлекләр бирүенә, киләчәктә үз-үзеңне табуда ярдәм итүенә инана төштем. Әлеге юнәлеш, әлеге агым яшьләр өчен бик кирәк.

**– Ятып калганчы атып кал, дигән девиз белән яшәүче Гөлназга мин дә бу изге һәм абруйлы эшендә уңышлар телим!**

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: И.Вәлиев, Р.Габдрахманова, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.